# **КАРАР**
# **Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**

Азнакай шәһәре №_235-34____ «15» февраль 2019 ел

Азнакай район Советының 2011 елның 20 апрелендәге 48-8 номерлы Карары белән расланган «Азнакай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (2014 елның 10 апрелендәге 297-42 номерлы, 2014 елның 22 маендагы 306-44 номерлы карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар чыгарды**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2011 елның 20 апрелендәге 48-8 номерлы карары (10.04.2014 ел, №297-42, 22.05.2014 ел, №306-44 карарлары редакциясендә) белән расланган «Азнакай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2.1.7 пунктны «һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджеты акчаларының Баш администраторлары тарафыннан эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыруны анализлау.» дигән сүзлзр белән тулыландырырга;.

1.2. 3.2 пунктта.:

түбәндәге эчтәлекле 3.2.30, 3.2.31, 3.2.32 пунктчалар өстәргә:

«3.2.30. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының чыгым йөкләмәләре реестрын алып бара;

3.2.31. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы бюджеты акчаларының Баш администраторлары тарафыннан эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын гамәлгә ашыруны анализлый;

3.2.32. үз компетенциясе кысаларында Россия Федерациясе законнары нигезендә административ хокук бозулар эшләре буенча җитештерүне гамәлгә ашыра;»;

3.2.30 пунктчаны 3.2.33 пунктча дип санарга;

1.3. 3.3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Эчке муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча палатаның вәкаләтләре булып тора:

Россия Федерациясе Бюджет законнары һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка норматив хокукый актлар үтәлешен тикшереп тору;

муниципаль программаларны гамәлгә ашыру турында хисапларның, шул исәптән муниципаль биремнәрнең үтәлеше турындагы хисапларның тулылыгын һәм дөреслеген контрольдә тоту;

"Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясындагы 8 өлеше нигезендә контроль.».

2. Әлеге карарны Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http:/aznakayevo.tatar.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин